СОВЕТ СТАРОЧУРИЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Новая, д.52, с. Старое Чурилино, Арский муниципальный район, 422014

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ЧҮРИЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Яңа урамы, 52 нче йорт, Иске Чүриле авылы, Арча муниципаль районы, 422014

Тел. (84366)57-3-48, 3-06-09 факс (84366)57-3-48, 3-06-09 E-mail: Schur.Ars@tatar.ru.

**Иске Чуриле авыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

**« 20 » февраль 2020 ел** **№ 97**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Иске Чуриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иске Чуриле авыл җирлеге Советының 2018 елның 20 декабрендәге 70 номерлы карары белән расланган муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (16.04.2019 ел, № 73, 08.11.2019 ел, № 92 номерлы үзгәрешләр белән)**

«Коррупциягә каршы көрәш турындагы Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чуриле авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы « Иске Чуриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иске Чуриле авыл җирлеге Советының 2018 елның 20 декабрендәге 70 номерлы карары белән расланган муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә (16.04.2019 ел, № 73, 08.11.2019 ел, № 92 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1) 11 статьяның 11.1 пунктының 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

2) түбәндәге очраклардан тыш, коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга:

а) сәяси партия, һөнәр берлеге органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы тарафыннан түләүсез идарә итүдә катнашу, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак төзелеше, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтенең гомуми җыелышында (конференция) катнашу;

б) Россия Федерациясе субъекты законында билгеләнгән тәртиптә яллаучы вәкиленнән алынган рөхсәт белән коммерциячел булмаган оешма белән түләүсез идарә итүдә катнашу (сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы тарафыннан, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтенең гомуми җыелышында (конференция) катнашудан тыш;

в) Россия Федерациясе субъектының муниципаль берәмлекләре советында, башка муниципаль берәмлекләрнең берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә чагылдыру;

г) муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталындагы өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә гамәлгә куючысы (акционер, катнашучы) муниципаль берәмлек булган оешманың ревизия комиссиясендә һәм идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә чагылдыру;

д) федераль законнарда каралган башка очракларда.

**2) 11 статьяның 11.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 2_1 пункт өстәргә:**

2_1) шәхсән яки ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә;

**3) 15 статьяның 15.3 пунктының 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

"4) хезмәт кенәгәсен һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләрне (Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 66_1 статьясы), хезмәт килешүе беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш;»;

**4) 23 статьяның 23.2 пунктының 9 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«Бүләкләү хокукый акт белән игълан ителә, хезмәткәргә җиткерелә һәм хезмәт кенәгәсенә (Хезмәт кодексы, башка федераль закон нигезендә хезмәткәрнең хезмәт кенәгәсе рәсмиләштерелмәгән очраклардан тыш) һәм муниципаль хезмәткәрнең шәхси эшенә кертелә (акчалата бүләкләүләрдән тыш).»;

5) **24 статьяның 24.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«24.3. Дисциплинар җәза куллану һәм юкка чыгару тәртибе хезмәт законнары белән билгеләнә, "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очраклардан тыш.»;

**6) 25 статьяның 25.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 2 абзац өстәргә:**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 14_1, 15 һәм 27 статьяларында каралган җәзалар муниципаль хезмәткәр тарафыннан коррупциячел хокук бозу турында мәгълүмат кергән көннән алып алты айдан да соңга калмыйча, муниципаль хезмәткәрнең эшкә вакытлы сәләтсезлеге, аның чираттагы ялда булу чорын исәпкә алмыйча, һәм коррупциячел хокук бозу көненнән өч елдан да соңга калмыйча кулланыла. Күрсәтелгән вакытка җинаять эше буенча эшләр башкару вакыты кертелми.»;

**7) 30 статьяның 30.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«30.4. муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматларны алып бару (Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 66_1 статьясы);".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http:arsk.tatarstan.ru), гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: һәм РТ, Арча районы, Иске Чүриле авылы, Яңа урам, 52 йорт; Штерә авылы, Советлар урамы, 30 йорт; Ашабаш авылы, Комсомол урамы, 4а йорты; Венета авылы, Үзәк урам, 13 йорт адреслары буенча мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Иске Чуриле авыл җирлеге башлыгы,
Иске Чуриле Советы рәисе Р.Т. Хидиятуллин

СОВЕТ СТАРОЧУРИЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1609012646